**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 6 июль № 491

г. Казань

«Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен ябу турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен (алга таба – «Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ) гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 15 сентябреннән «Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ ябу турындагы карарын кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

унудүрт көн эчендә:

«Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ ябу комиссиясе составын расларга;

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нигезендә, «Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ ябу тәртибен һәм вакытларын билгеләргә;

«Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ ябу турында карар кабул ителгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә теркәү органына, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен, «Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ ябылу процессында тора дигән мәгълүмат тапшырырга;

утыз көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына ябыла торган учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтеннән, шул исәптән

күчемсез һәм аеруча кыйммәткә ия мөлкәттән, алга таба файдалану турында тәкъдимнәр кертергә;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, ябылу нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә, шулай ук «Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ ябу буенча законнар белән күздә тотылган бүтән чараларны гамәлгә ашырырга;

картлар һәм инвалидлар интернат йортларында буш урыннар барлыгы турында тармак банкы нигезендә, гражданнарны «Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесеннән Татарстан Республикасының картлар һәм инвалидлар интернат йортларына күчерергә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына алтмыш көн эчендә элек «Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ беркетелгән Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тәкъдим иткән исемлек нигезендә, законнар белән билгеләнгән тәртиптә күчерүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенә, «Аксубай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ ябу буенча чаралар тәгәлләнгәннән соң, бер ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 804 нче карарына тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карап тикшерүенә билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

5. Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгына 2015 елга һәм 2016 һәм 2017 елларга план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджеты исемлегенә үзгәрешләр кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\491.docx